**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

| “КАРАЛДЫ” | **“КИЛЕШЕНДЕ”** | **“РАСЛАНДЫ”** |
| --- | --- | --- |
| МБ җитәкчесе | «2 нче Алексеевск УГББМ” МБГБУ директор урынбасары | «2 нче Алексеевск УГББМ” МБГБУ директоры |
| ________Замалиева И.Х | ________Ягудина Л.Р. | ________Липлянина Л.Н. |
| МБ утырышы беркетмәсе № 1 25 август 2016 ел | 27 август 2016 ел | ____ номерлы боерыгы |
| | | 31 август 2016 ел |

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Хөснетдинова Гөлия Сөләймановнаның**

**1 “А” сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби укудан**

**эш программасы**

Педагогик совет утырышында каралды

1 номерлы беркетмә

31 август 2016 ел

2016-2017 уку елы

## I. Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре.

**Сыйныф**: 1-а
**Укытучы:** Хуснутдинова Г.С..
**Уку планы буенча** **татар теле һәм укудан:***99сәг.*
**Атнага:***3сәг.*
**Күчереп язу:***1*
**Дәреслек -** Р.З.Хәйдәрова, Н.Г.Галиева “Күңелле татар теле”. Дүртьеллык башлангыч рус мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби уку дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2013.

Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:

1. Программа: Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фәнминистрлыгы. Урта (тулы) гомумибелембирүмәктәбендәрустеллебалаларга татар теленкоммуникатив технология нигезендәукытупрограммасы (1 — 11 нчесыйныфлар). Төзүче – авторлары: Р.З. Хәйдәрова, Р. Л. Малафеева, 2014 ел.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нчеуртагомумибелембирүмәктәбе”неңтөпгомумибелембирүбаскычындабашлангычго мумибелембирүпрограммасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомумибелемучреждениясе “Аерымпредметларнытирәнтенөйрәнүче Алексеевск 2 нчеуртагомумибелеммәктәбе”нең 2016-2017укуелынаукытупланы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел).

“Татар теле һәм әдәби уку” предметы буенча 1 нче сыйныф программасын үзләштерүнең **шәхси нәтиҗәләре**:

– татар теленең дәүләт теле буларак ролен аңлау;
– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру;
– татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру.
--Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау.

Татар теленә өйрәтүнең **метапредмет (***регулятив, коммуникатив, танып-белү)* **нәтиҗәләре**:

–укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
–эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
–дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
–дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;
–әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;
–парларда һәм күмәк эшли белү;
–әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;
–үрнәк буенча эшли белү;
–аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
–рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
–аңлап укый белү;
–укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирү - чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру

Татар теленә өйрәтүнең **предмет нәтиҗәләре**.

**Сөйләшү**

**Диалогик сөйләм.** 1 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү

ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм.** Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**Ишетеп аңлау (аудирование)**

Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**Уку**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.

**Язу**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбендәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау язу.

**<u>Укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр</u>**

**Тыңлап аңлау**

-Укытучының дәрес, уен ситуацияләре белән бәйле сорауларын, күрсәтмәләрен аңлау;

-тыңлаганда җөмлә, сүз чикләрен билгеләү, интонацияне аеру;

-сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетеп аера белү.

-сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү;

-ишеткән сөйләмнең, җөмләнең эчтәлегенә төшенү.

**Диалогик сөйләм:**

-Өйрәнелгән эчтәлек нигезендә әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;

-программада күрсәтелгән темалар буенча укытучының сорауларына җавап бирү һәм

сораулар куя белү;

-дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм**

-Җанлы һәм җансыз предметларны,рәсем, картина эчтәлеген сурәтләп сөйли белү;

-тәкъдим ителгән план, терәк сүзләр ярдәмендә укылган өзек яисә караган рәсем буенча, өйрәнелгән җөмлә төрләрен файдаланып, хикәя төзү;

-укыган хикәяләрнең эчтәлеген сөйли белү;

-үзе, гаиләсе һәм дуслары турында кечкенә информация бирә белү.

**Уку**

-Татар алфавитындагыхәрефләрнетаныйбелү;

-хәреф-авазсистемасынаера, татар теленәхасбулганавазларныдөресәйтепукыйбелү;

-дәреслектәукуөченбирелгәнҗөмләләрне, текстларныдөрес интонация беләнукыйбелү;

-текстгагытынышбилгеләренә карата тиешле пауза һәминтонацияләрнеүтәү,өтерләрянындагысүзләрнетиңдәшлек, эндәшүинтонацияләребеләнуку;

-укыганматериалныңэчтәлегеннәнкирәклемәгълүматныаерып ала белү;

-кечкенәкүләмлешигырьләрнеяттансөйләү;

-укыгандасүзлекләр5улана белү.

**Язу**

-Татаралфавитындагыхәрефләрне дөрес, матур яза белү;

-дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;

-бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;

-конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;

-программада күрсәтелгән темалар буенча, терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

**<u>Уку елы ахырына универсаль уку гамәлләре формалаштыру. УУГ.</u>**

**Шәхси нәтиҗәләр.**

**Шәхси универсаль уку гамәлләре:**

- “Гаилә”, “туган ил”, “мәрхәмәтлелек”, “башкаларга карата түземлелек” төшенчәләрен кабул итү, аларның кадерен белү;

- Туган республикага, гаиләгә, туганнарга карата хөрмәт, әти-әнине ярату; үз милләтеңне ярату, татар булуың белән горурлану;

- укуга карата кызыксыну хисе булу, укучы ролен үзләштерү;

- әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләрен һәм геройларның гамәлләренә кешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;

**Предметара нәтиҗәләр.**

**Регулятив универсаль уку гамәлләре:**

- Эшчәнлек өчен эш урынын әзерләү.
- Укытучы ярдәме белән эшне планлаштырырга өйрәнү.
- Укытучы ярдәмендә эшнең дөреслеген тикшерү.
- Эш сыйфатына бәя бирә белү.
- Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү.( линейка, бетергеч, карандаш, )

**Танып белү универсаль уку гамәлләре:**

- Дәреслек белән эш итә белү.
- Хәрефләрне танып, текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
- Этнокультура өлкәсенә караган сүзләр булган текстны, сүзлекләр кулланып, аңлап уку.
- Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
- Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
- Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.

- Предметларны, чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
- Укылган яки тыңланган зур булмаган текстның эчтәлеген сөйли белү.

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:**

- Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү
- Укытучының, классташларның сорауларына җавап бирү;
- Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
- Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
- Парларда эшли белү

## II. Укыту предметының эчтәлеге

УМК өчен материал 1сыйныф балаларының аралашу сфераларын исәпкә алып сайланды.

Дәреслеккә түбәндәге аралашу темалары кертелде: “Әйдәгез танышабыз!”, “Урман дусларыбыз”, “Спорт бәйрәме”, “Мәктәптә”, “Йорт хайваннары һәм кошлары”, “Бакчада”,” Кыш җитте”, “Сәламәт бул!”, “Безнең гаилә”, “Татар халык ашлары”, “Без шәһәрдә яшибез”, “Кибеттә”, “Җәй”темалары кертелде. Дәреслеккә кызыклы сораулар, чагыштыруны, анализлауны, логик фикерләүне таләп иткән төрле биремнәр кертелде. Мондый биремнәрне балалар кызыксынып эшлиләр, шул ук вакытта өйрәнелгән сөйләм үрнәкләре дә кабатлана. Мәктәпнең укыту планы нигезендә 1 сыйныфта татар теле һәм әдәби укуны өйрәнүгә атнага 4 сәг вакыт бирелә, елга барлыгы 132 сәг.Әйдәгез танышабыз! (14 сәгать),Урман дусларыбыз (6 сәгать),Спорт бәйрәме (10 сәгать),Йорт хайваннары һәм кошлары (12 сәгать),Мәктәптә (7 сәгать),Сәламәт бул (9 сәгать),Безнең гаилә (11 сәгать),Татар халык ашлары (8 сәгать),Кибеттә (12 сәгать)Без шәһәрдә яшибез (8 сәгать),Җәй җитә (8 сәгать) темалары буенча үткәрелә.

Һәр дәрестә сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре дә катнаша, һәм дәрес максатында күрсәтелгән сөйләм дозасы сөйләм эшчәнлегенең дүрт төре аша да үтеп чыга. Аралашу процессы сөйләшү (диалогик, монологик сөйләм), ишетеп аңлау, уку һәм язу аша оештырыла. Алар арасында төп урынны сөйләшү алып тора.

| № | Дәрес темасы | Укучыларның эшчәнлеге яки уку эшчәнлеге | Дата |
|---|---|---|---|
| 1-2 | Әйдәгез, танышабыз! | Исәнләшә, саубуллаша белү Әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, хәлен сорый белү. Әңгәмәдәшеңнең яшәү урынын сорый һәм үзеңнең кайда яшәвең турында хәбәр итә белү. | 1.09<br>5.09 |
| 3. | Синең исемең ничек? соравына һәм аңа җавап формасы. | Бер-береңнең исемен сорау, яшәү урынын әйтә белү. | 7.09 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | Бу кем? соравы һәм аңа җавап формасы | Бу кем? Бу нәрсә сорауларыны җавап бирә белү. | 8.09 |
| 5. | Раслау һәм кире кагу формалары | Әйе, юк сүзләрен кулланып диалог төзү. | 12.09 |
| 6. | -мы/-ме сорау кисәкчәләре | | 14.09 |
| 7. | Әйдәгез, танышабыз! | | 15.09 |
| 8. | Татарстан шәһәрләре | Татарстан шәһәрләре исемнәрен әйтү. | 19.09 |
| 9. | Син кайда яшисең? соравы һәм аңа җавап формасы | Син кайда яшисең? Соравын куя һәм аңа җавап бирә белү | 21.09 |
| 10. | “Әйдәгез, танышабыз!” темасын йомгаклау | Алган белемнәрне куллана алу | 22.09 |
| 11. | Кыргый хайваннар. Аа хәрефе | Кыргый хайваннарның исемен атый, санын әйтә белү. Аа хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 26.09 |
| 12. | Урман дусларыбыз. Әә хәрефе | Кайда? Кайда яши? сораулары һәм аларга өйрәнелгән сүзләр белән җавап бирә белү. Әә хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 28.09 |
| 13 | Нинди? соравы һәм аңа җавап формасы. Оо хәрефе | Хайваннарның кайда яшәгәнен әйтә, аларны сүрәтли белү. Оо хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 29.09 |
| 14. | Рус халык әкияте “Төремкәй”. Өө хәрефе | “Төремкәй” әкиятенең эчтәлеген искә төшерү. Өө хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең | 3.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | язылышын яттан белү. | |
| 15. | Боерык фигыльнең 2нче зат берлек сан формасы. Нн, ң хәрефләре. | Иптәшеңә командалар бирә белү. Нн, ң хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 5.10 |
| 16. | Боерык фигыльнең 2нче зат берлек сан формасы. Ии, Ыы хәрефләре. | Әле кисәкчәсен боерык фигыльнең II зат берлек сан формасы белән куллану. Ии, Ыы хәрефләре.Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 6.10 |
| 17. | Дустыңны урамга уйнарга чакыру. Уу хәрефләре | Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү Дустыңны урамга уйнарга чакыра белү. Уу хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 10.10 |
| 18 | Ризалык белдерү формасы. Үү хәрефе | | 12.10 |
| 19. | Ничә? соравы, аңа җавап формасы. Тт хәрефе. | Тт хәрефе.Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү Кем белән уйныйсың? Соравын әйтә, аңа җавап бирә белү күнекмәләрен формалаштыру; уйный фигыленең I, II затларда төрләнеше белән таныштыру. Лл хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 13.10 |
| 20. | Уйный фигыленең I, II затларда төрләнеше. Лл хәрефе. | | 17.10 |
| 21. | Тәртип саннары. Кк хәрефе | Тәртип саннарын сөйләмдә куллану белән таныштыру. Ничә? соравына җавап бирә белү; Һәр хәрефне дөрес әйтеп | 19.10 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү предметларның санын әйтә белү. Кк хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | |
| 22 | Уку-язу әсбаплары. Мм хәрефе. | Уку-язу әсбапларының исемен, төсен, барлыгын, юклыгын әйтә белү. Мм хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 20.10 |
| 23 | Уку-язу әсбапларының кирәклеген әйтү, үзеңә сорап алу белү формасы. Сс хәрефе | Уку-язу әсбапларының кирәклеген әйтә, иптәшеңә тәкъдим итә, үзеңә сорап алу белү. Сс хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 24.10 |
| 24. | Без дәрестә. Рр хәрефе | Мәктәптәге уку хезмәтен атый белү. Рр хәрефе Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 26.10 |
| 25. | Без ничек укыйбыз? | Үзеңнең һәм иптәшеңнең ничек укыганын әйтә белү | 27.10 |
| 26. | “Мәктәптә” темасын йомгаклау | Предметларның урынын, санын әйтә белү | 7.11 |
| 27. | Йорт хайваннары һәм кошлары. Вв хәрефләре | Йорт хайваннарының һәм кошларының исеменәрен әйтә, саный белү. Вв хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең | 9.11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | язылышын яттан белү. | |
| 28. | Яши фигыленең берлек сан, I, II зат формасы | Яши фигылен I, II затта куллану; Кайда? соравына җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү | 10.11 |
| 29. | Кая? соравы һәм аңа җавап формасы. Гг хәрефләре. | Хайваннарны сүрәтли белү. Кая? соравын үзләштерү һәм аңа җавап буларак, исеменәрнең юнәлеш килеше формасы белән таныштыру. Гг хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 14.11 |
| 30. | Кая? Кемгә? сораулары һәм аларга җавап бирү. Дд хәрефләре. | Кая? Кемгә? сорауларын үзләштерү һәм, аларга җавап буларак, исемнәрне юнәлеш килешендә куллануны камилләштерү. Дд хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 16.11 |
| 31. | Иптәшеңнең һәм үзеңнең нәрсә яратканыңны әйтү һәм сорау. Зз хәрефләре | Иптәшеңнең һәм үзеңнең нәрсә яратканыңны әйтә һәм сорый белү. Зз хәрефләре.Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 17.11 |
| 32. | Кайдан? соравы һәм аңа җавап формасы. Бб хәрефләре. | Иптәшеңнең кайдан кайтканын сорый һәм үзеңнең кайдан кайтканыңны әйтә белү. Бб хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 21.11 |
| 33. | Кая? Кайда? Кайдан? | Кая барганыңны, кайда торганыңны, | 23.11 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сораулары һәм аларга җавап формасы. Пп хәрефләре | кайдан кайтканыңны әйтә белү. Пп хәрефләре Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | |
| 34. | Исемнәрнең I зат берлек сан тартым белән төрләнеше. Ээ хәрефләре. | Предметларның үзеңнеке булуын әйтергә өйрәтү. Исемнәргә I зат берлек сан тартым кушымчалары ялгану тәртибе белән таныштыру. Ээ хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 24.11 |
| 35. | Тыныч йокы, хәерле иртә теләү. Ее, Йй хәрефләре. | Тыныч йокы, хәерле иртә теләү. Ее, Йй хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 28.11 |
| 36. | Яшелчәләр. Жж хәрефләре | Жж хәрефе. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү Яшелчә исеменнәрен, санын, аларның төсен, тәмен әйтә, аларны сорап ала белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 30.11 |
| 37. | Кирәк, кирәкми сүзләре | | 1.12 |
| 39. | Нинди? соравы һәм аңа җавап формасы. Шш хәрефләре | | 5.12 |
| 40. | Нәрсә яратканны, яратмаганны әйтү, сорау формалары. Щщ хәрефләре | Нәрсә яратканыңны, яратмаганыңны әйтә, сорый белү. “Щи” текстын сөйли белү Щщ хәрефләре Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 7.12 |
| 41. | Нәрсә яратканны, яратмаганны әйтү, сорау | Нәрсә яратканыңны, яратмаганыңны әйтә, сорый белү. “Щи” текстын сөйли белү | 8.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | формалары. Щщ хәрефләре | Щщ хәрефләре .Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | |
| 42. | Безнең бакчада. Чч хәрефләре | Чч хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 12.12 |
| 43. | Кем? Нәрсә? Нишли? сораулары һәм аларга җавап формалары | Кем? Нәрсә? Нишли? сорауларына җавап бирә белү күнекмәләрен үстерү. Хезмәтенә карап, геройга бәя бирә белү | 14.12 |
| 44. | Кыш билгеләре. Хх хәрефләре | Кыш билгеләрен әйтә, кышкы уенга чакыра, көн нинди булуын сорый белү. Хх хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 15.12 |
| 45. | Кышкы уенга чакыру | | 19.12 |
| 46. | Кыш бабай килә. Һһ хәрефләре | Кыш бабай, Кар кызы исемнәрен әйтә, Кыш бабайга хат яза, Кыш бабайдан бүләк сорап ала белү. Һһ хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү | 21.12 |
| 47. | Минем чанам бар төзелмәсе. Фф хәрефләре | Чана, чаңгы, тимераяк сүзләрен әйтә белү. Бу предметларның барлыгын, юклыгын, нәрсә белән шуганыңны әйтә белү. Фф хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 22.12 |
| 48. | Кышкы уеннар | | 9.01 |
| 49. | -мы/-ме сорау кисәкчәләрен кулланып, | -мы/-ме сорау кисәкчәләрен кулланып, сорау бирү | 11.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сорау бирү; раслау һәм инкарь итү. Цц хәрефләре | күнекмәләрен камилләштерү; раслау һәм инкарь итә белү күнекмәләрен үстерү. | |
| 50. | Кая? Кайда кайдан сорауларына җавап бирү | Кая? Кайда кайдан сорауларына җавап бирә белүне камилләштерү . Цц хәрефләре .Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 12.01 |
| 51. | Бәйрәмдә. Яя хәрефләре | Яңа ел бәйрәме турында сөйли белү. Яя хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 16.01 |
| 52. | Бәйрәмгә барабыз. Юю хәрефләре | Бәйрәмгә барганыңны, бәйрәмнең кайда булганын әйтә белү. Һава торышын тасвирлый белү. Юю хәрефләре. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 18.01 |
| 53. | Төсләр. Нечкәлек һәм калынлык билгеләре. | Предметларның төсен әйтә белү. Бер-береңнең яшен сорый белү.<br>Бер-береңне уенга чакыра белү. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең язылышын яттан белү. | 19.01 |
| 54. | Татар алфавитындагы хәрефләр тәртибе | Татар алфавитындагы хәрефләр тәртибе белән таныштыру. | 23.01 |
| 55. | Татар теленә хас авазларны кабатлау | Татар теленә генә хас авазларны дөрес әйтә белү күнекмәләрен үстерү. Һәр хәрефне дөрес әйтеп уку. Аваз һәм хәрефләрне аера белү. Хәрефләрнең | 25.01 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | язылышын яттан белү. | |
| 56. | Тән әгъзалары исемнәре | Тән әгъзалары исемнәрен әйтә белү | 26.01 |
| 57. | Авырта фигыленең юклык формасы | Кай җиреӊ авыртканын сорый, әйтә белү | 30.01 |
| 58. | Сәламәт бул! | Сәламәт булу өчен киңәшләр бирә белү. Авыру кешенең хәлен сорау, аңа дару бирү | 1.02 |
| 59. | Сәламәт булу өчен киңәшләр бирү | | 2.02 |
| 60. | Шәхси гигиена предметлары | Шәхси гигиена предметларының исемнәрен әйтә, аларның барлыгын, юклыгын, кирәклеген әйтә, аларны сорап ала белү. | 6.02 |
| 61. | Шәхси гигиена предметларын сорап алу | | 8.02 |
| 62. | Мин сабын белән кул юам төзелмәсе | Мин сабын белән кул юам төзелмәсе белән таныштыру | 9.02 |
| 63. | Гаилә | Гаилә әгъзаларының исемнәрен атый, үз гаиләң турында сөйли белү, иптәшеңнең гаиләсе турында сорый белү | 20.02 |
| 64. | Минем гаиләм | | |
| 65. | Гаиләдә кемнәр барлыгын әйтү, сорау | Гаиләдә кемнәр барлыгын әйтә, сорый белү, гаилә әгъзаларының нишләгәнен әйтә белү | 22.02 |
| 66. | Яз фасылы | Яз фасылы турында, язгы көнне сүрәтләп сөйли белү | 23.02 |
| 67. | Язгы көн | | |
| 68. | Һава торышы | Һава торышын сорый, урамга чакыра белү. Язның ошаганын, ошамаганын әйтә белү | 27.02 |
| 69. | 8нче Март – әниләр бәйрәме | Бәйрәм белән котлый белү. Син алмашлыгын төшем | 1.03 |
| 70. | Бәйрәм белән | | 2.03 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | котлый белү | килешендә куллануны үзләштерү | |
| 71. | Мин бүләк бирәм | Кемгә бүләк бирүне әйтә белү. Сөйләмдә “тәмле сүзләр”не куллана белү | 6.03 |
| 72. | Татар халык ашлары | Табынга чакыра, татар халык ашларының исемнәрен әйтә, ризыкларның тәмле булуын әйтә белү | 8.03 |
| 73. | Ризыкларның тәмле булуын әйтү | Нинди ризыклар яратканыңны, нинди ризык кирәк икәнен, нәрсә белән чәй эчкәнеңне әйтә белү | 9.03 |
| 74. | Кунакта | Нинди ризыклар яратканыңны, нинди ризык кирәк икәнен, нәрсә белән чәй эчкәнеңне әйтә белү | 13.03 |
| 75. | Кунакны каршы алу | Кунакларны каршы ала белү, аларны табынга чакыра белү; -мы/-ме сорау кисәкчәләрен кулланып мәгълүмат ала белү күнекмәләрен камилләштерү | 15.03 |
| 76. | -мы/-ме сорау кисәкчәләрен кулланып мәгълүмат алу | | 16.03 |
| 77. | Туган көн – зур бәйрәм | Туган көн турында сөйли, туган көн белән котлый белү | 29.03 |
| 78. | Ашамлыклар | Эч, аша фигыльләрен I, II, III затта берлек санда куллана белү Азык-төлек исемнәрен, нәрсә ашаганыңны, эчкәнеңне әйтә белү. Кибеттә сатып ала белү | 30.03 |
| 79. | Эч, аша фигыльләрен I, II, III затта берлек санда куллану | | 3.04 |
| 80. | Ашамлыклар кибетендә | | 5.04 |
| 81. | Савыт-саба | Савыт-саба исемнәрен дөрес әйтә белү; Мин пычак белән ипи кисәм; Мин кашык белән аш ашыйм төзелмәләрен сөйләмдә куллана белүне формалаштыру | 6.04 |
| 82. | Кибеттә савыт-саба сатып алу | | 10.04 |
| 83. | Савыт-саба кибетендә | Ничә? Ничә сум? Сорауларын сөйләмдә | 12.04 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | куллана һәм аларга җавап бирә белү | |
| 84. | Киемнәр | Кием исемнәрен дөрес әйтә белү; исемнәрнең I, II, III зат берлек санда тартым белән төрләнешен сөйләмдә куллануны камилләштерү | 13.04 |
| 85. | Исемнәрнең I, II, III зат берлек санда тартым белән төрләнеше | | 17.04 |
| 86. | Киемнәр кибетендә | | 19.04 |
| 87. | Шәһәрдә | Киемнәрнең исемен, төсен, нинди кием кигәнеңне әйтә белү | 20.04 |
| 88. | Безнең шәһәр<br>Кайда? соравы | Кая? Кайда? Кайдан? Сорауларына җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү;<br>Чиста, матур, кечкенә, зур, пычрак сыйфатларын кулланып, сүрәтли белү күнекмәләрен үстерү | 24.04 |
| 89. | | Кайда? Соравына җавап бирә белү күнекмәләрен камилләштерү | 26.04 |
| 90 | “Татарстан шәһәрләре” темасын кабатлау | Татарстан шәһәрләре исемнәрен дөрес әйтә белү; исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә куллану күнекмәләрен камилләштерү | 27.04 |
| 91. | Җәй җитә | Җәй турында сөйли белү күнекмәләрен формалаштыру;<br>Аңлап, сәнгатьле укый белү күнекмәләрен формалаштыру | 1.05 |
| 92. | Җәйге ял | | 3.05 |
| 93. | Җәйге ял | | 4.05 |
| 94. | Без Сабантуйга барабыз | Дусларны Сабантуй бәйрәменә чакыра белү; бәйрәмдә нишләгәнеңне әйтә белү | 8.05 |
| 95. | Сабантуй. Йомгаклау | | 10.05 |
| 96. | Йомгаклау | | 11.05 |
| 97-99 | Резерв дәресләр | Белемнәрне системалаштыру | 15.05<br>17.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 18.05 |